СОВЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422060, Республика Татарстан, Сабинский район,
п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru, www.saby.tatarstan.ru

№ 330 от 17.12.2019
на № __от __________

# К А Р А Р

Саба муниципаль район Советының “Муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан аларның вазыйфаи хәленә яисә аларның хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә, бүләк алу һәм аны тапшыру, бүләкне бәяләү, аны сатудан алынган акчаларны сатып алу һәм күчерү турында хәбәр итүе тәртибе хакында”гы 2014 елның 25 февралендәге 239 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, “Коррупциягә каршы тору турында “ 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль законы, “Беркетмә чараларына, хезмәт командировкаларына һәм анда катнашу аларның хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәү, бүләкне тапшыру һәм бәяләү,аны сатудан кергән акчаларны сатып алу һәм күчерү белән бәйле башка рәсми чараларга бәйле рәвештә бүләк алу турында аерым категория затларның хәбәр итү тәртибе турында” Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 9 гыйнварындагы 10 номерлы карары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

**1.** Саба муниципаль район Советының “Муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан аларның вазыйфаи хәленә яисә аларның хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә, бүләк алу һәм аны тапшыру, бүләкне бәяләү, аны сатудан алынган акчаларны сатып алу һәм күчерү турында хәбәр итүе тәртибе хакында”гы 2014 елның 25 февралендәге 239 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1.1.** карарның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Беркетмә чараларына, хезмәт командировкаларына һәм анда катнашу аларның хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәү, бүләкне тапшыру һәм бәяләү,аны сатудан кергән акчаларны сатып алу һәм күчерү белән бәйле башка рәсми чараларга бәйле рәвештә бүләк алу турында аерым категория затларның хәбәр итү тәртибе турында”;

**1.2.** карарның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1. Беркетмә чараларына, хезмәт командировкаларына һәм анда катнашу аларның хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәү, бүләкне тапшыру һәм бәяләү,аны сатудан кергән акчаларны сатып алу һәм күчерү белән бәйле башка рәсми чараларга бәйле рәвештә бүләк алу турында аерым категория затларның хәбәр итү тәртибе турындагы Нигезләмәне расларга”;

**2.** Саба муниципаль район Советының “Муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан аларның вазыйфаи хәленә яисә аларның хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә, бүләк алу һәм аны тапшыру, бүләкне бәяләү, аны сатудан алынган акчаларны сатып алу һәм күчерү турында хәбәр итүе тәртибе хакында”гы 2014 елның 25 февралендәге 239 номерлы карары белән расланган, муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан аларның вазыйфаи хәленә яисә аларның хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә, бүләк алу һәм аны тапшыру, бүләкне бәяләү, аны сатудан алынган акчаларны сатып алу һәм күчерү турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**2.1**. нигезләмә исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Беркетмә чараларына, хезмәт командировкаларына һәм анда катнашу аларның хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәү, бүләкне тапшыру һәм бәяләү,аны сатудан кергән акчаларны сатып алу һәм күчерү белән бәйле башка рәсми чараларга бәйле рәвештә бүләк алу турында аерым категория затларның хәбәр итү тәртибе турындагы Нигезләмә”;

**2.2.** Нигезләмәнең 2 пунктындагы икенче абзацында “хәлиткеч тавыш хокукы белән” сүзләрен “комиссиядә даими (штат) нигездә эшләүче хәлиткеч тавыш хокукы белән” сүзләренә алмаштырырга**.**

**2.3.** Нигезләмәнең 2 пунктындагы бишенче абзацында “вазыйфаи хәле белән бәйле яисә хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә” сүзләрен “беркетмә чараларына, хезмәт командировкаларына һәм анда катнашу аларның хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәвенә бәйле башка рәсми чараларга бәйле рәвештә” сүзләренә алмаштырырга;

**2.4.** 3 пунктта “аларның вазыйфаи хәленә яисә хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә” сүзләрен “аларның вазыйфаи хәле яисә аларның хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәве белән бәйле рәвештә, беркетмә чараларына, хезмәт командировкаларына һәм анда катнашу аларның хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле башка рәсми чаралар белән бәйле рәвештә бүләк алудан тыш» сүзләренә алмаштырырга;

**2.5**. 4 пунктта “вазыйфаи хәле белән бәйле яисә хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә” сүзләрен “беркетмә чараларына, хезмәт командировкаларына һәм анда катнашу аларның хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәвенә бәйле башка рәсми чараларга бәйле рәвештә” сүзләренә алмаштырырга;

**2.6.** 5 пунктта “вазыйфаи хәле белән бәйле яисә хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә” (алга таба – хәбәрнамә) сүзләрен “беркетмә чараларына, хезмәт командировкаларына һәм анда катнашу аларның хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәвенә бәйле башка рәсми чараларга бәйле рәвештә” сүзләренә алмаштырырга (алга таба – хәбәрнамә);

**2.7**. Нигезләмәнең 1 кушымтасында “аларның вазыйфаи хәленә яисә хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә” сүзләрен “аларның вазыйфаи хәле яисә аларның хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәве белән бәйле рәвештә, беркетмә чараларына, хезмәт командировкаларына һәм анда катнашу аларның хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле башка рәсми чаралар белән бәйле рәвештә бүләк алу турында” сүзләренә алмаштырырга;

**3**. Әлеге карарны Интернет челтәрендә - Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

**4.** Әлеге карар рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

Саба муниципаль
районы Башлыгы Р.Н. Минниханов